Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел №114

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә
муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә»
2016 ел, 28 декабрь 60 карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 июлендәге 132 номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокурорының 2018 елның 27 февралендәге 134 номерлы күрсәтмәсен күздә тотып

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында»гы 60 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 30 мартындагы 74, 2017 елның 5 маендагы 78, 2017 елның 31 маендагы 83, 2017 елның 25 сентябрендәге 91 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 9 бүлек кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 9.18 пунктын өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге мәгълүматлар муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт үткән җирле үзидарә органы тарафыннан кертелә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 15 статьясында каралганча ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Шәйхулова Ф.Х.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н. А. Бочкарев).

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин